# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **07.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге
составына керүче Якты-Күл авылында
2020 елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты - Күл авылында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Үчәлле авыл җирлеге Якты-Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Якты-Күл авылы Якты-Күл урамы буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Якты-Күл авылы территориясен куаклардан, чүп үләннәреннән чистарту һәм тоташ гербицид белән химик эшкәртү;
- Якты-Күл авылында юлларны кардан чистарту;
- Якты - Күл авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Якты - Күл авылында («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел») бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Якты - Күл авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Якты - Күл авылында ике телдә урам күрсәткечләрен һәм торак йортлар өчен номерларны сатып алу (әзерләү).
- Якты- Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы урнаштыру (материал сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Якты - Күл авылында Бөек Ватан сугышы ветераннары стендын бизәү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина